«Без – XXI гасыр киләчәге» V региональ  фәнни-гамәли конференциясе

# “Гамил Афзал иҗатында туган як  темасының чагылышы” темасына фәнни-эзләнү эше

Антонова Мария Александр кызы,
Рус Акташы гомуми урта белем бирү мәктәбенең
11 сыйныф укучысы

Фәнни җитәкче: Вафина Гөлнур Шамил кызы,
Әлмәт  муниципаль районы
Рус Акташы  гомуми урта белем бирү
мәктәбенең  югары  категорияле
татар теле һәм әдәбияты    укытучысы


# Фәнни эшнең максаты:

**язучының тормышы һәм иҗаты белән тирәнрәк танышу, туган якка мәхәббәт һәм Ватанга тугрылыклы булу хисләренең шигырьләрендә чагылышын ачыклау.**



# Теманың актуальлеге

***Гамил Афзал иҗатын өйрәнү - киләчәк буында туган җиргә, Ватанга мәхәббәт, татар халкының милли йолалары, гореф-гадәтләренә карата ихтирам тәрбияли.***



# ФӘННИ ЭШНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

- ***Кереш.***
- ***Төп өлеш.***

  ***I бүлек. Гражданлык лирикасы***

  ***II бүлек. Фәлсәфи лирика***

  ***III бүлек. Пейзаж лирикасы***
- ***Йомгаклау.***
- ***Кулланылган әдәбият исемлеге.***

# ТӨП ӨЛЕШ.
## ТУГАН ЯК ТЕМАСЫ ГАМИЛ АФЗАЛНЫҢ ГРАЖДАНЛЫК, ФӘЛСӘФИ, ПЕЙЗАЖ ЛИРИКАСЫНДА ЧАГЫЛЫШ ТАБА:

- **гражданлык лирикасында шагыйрь туган илгә тугрылык, милли рух, туган җиргә мәхәббәт темаларын ассызыклап үтә;**
- **пейзаж лирикасында ул туган як табигатенең гүзәллеген тасвирлый;**
- **фәлсәфи лирикасында кеше, яшәеш, галәм, яшәү мәгънәсе хакында уйланулар, туган ил – ватанга кагылышлы хис-кичерешләр бирелә.**

# I БҮЛЕК. ГАМИЛ АФЗАЛНЫҢ ГРАЖДАНЛЫК ЛИРИКАСЫНДА ТУГАН ЯК ТЕМАСЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ.




Гамил Афзал шигъриятенең асылын авыл тарихы, авыл тормышы билгеле.
Үзенең туган җирен, туган телен, халкын яратып, аларның язмышын иҗатында чагылдыра.
Шагыйрьнең “Туган туфрак”, “Милли рух”, “Ватаным Татарстан” шигырьләрендә туган җиргә мәхәббәт; аның героик үткәне һәм хәзергесе белән горурлану хисе ачык чагыла.

**Туган ягым, чирәм үскән урамыңда**

**Гармун уйнап, таңга чаклы урадым да,**

**Шөкер, дидем, шушы җирдә туганыма,**

**Күреп туймас таңнарыңны күргәнем бар.**

**(“Ватаным Татарстан”)**



## *“ТАТАРСТАН” ШИГЫРЕНДӘ ТУГАН ИЛГӘ ДАН ҖЫРЛАУ, ГОРУРЛЫК ХИСЕ СУРӘТЛӘНӘ*

Татарстан, күңелләргә шатлык тулып,

Бәйрәмеңдә котлыйм сине улың булып.

Көлеп торган чәчкәләрдән бәйләм сузып,

Сиңа, илем иң мөкатдәс гөлләрем бар.

**ШАГЫЙРЬ КЕШЕГӘ, АНЫҢ ХЕЗМӘТЕНӘ, АКЫЛЫНА ДАН ҖЫРЛЫЙ ҺӘМ КЕШЕ БӘХЕТЕ ӨЧЕН КӨРӘШӘ, ТУГАН ИЛЕБЕЗ БЕЛӘН ГРАЖДАННАРЧА ГОРУРЛАНА.**

**“Дөнья матур, дөнья киң” шигырендә автор:**

**Юллар үтәм, юллар үтәм,**
**Юллар чиге кайда, дим.**
**Нинди ил бар, нинди җир бар**
**Туган –үскән җиргә тиң! – дип яза.**

Гамил Афзал халкының батыр уллары турында онытмый. Аның Бөек Ватан сугышы герое Газинур Гафиятуллинның батырлыгына дан җырлаган “Газинур” шигыре; “газиз җанын өзеп утка аткан” шагыйрьләрнең батырлыгын тасвирлаган “Җәлилләрең, Такташларың“, “Туган илем“, “Муса Җәлил һәйкәле“ шигырьләре – моның ачык мисалы.

## II бүлек. Гамил Афзалның фәлсәфи лирикасында туган як темасының чагылышы.

**Гамил Афзалның лирик герое – кайнар йөрәкле, көчле шәхес. Шагыйрь игътибары гамәли эшнең нәтиҗәсен, гомум шатлыгын, тарихи агымдагы әһәмиятен ачуга юнәлтелә.**

**Көрәш белән, хезмәт белән еллар үтә,**
**Уйлый Кеше, эшли Кеше, иҗат итә;**
**Җир-ананы нурга урап, гөлгә төреп,**
**Тимер сугып, җырлар җырлап бәйрәм итә.**
**(“Дөнья көлсен”)**


. Әдипнең иҗатында– халык, милләт, җәмгыятьне борчыган заман, тормыш проблемалары яктыртыла.

Фәлсәфәне ничек кенә боргалама,
Берәр генә өч нәрсә бар бу дөньяда,
Иң кадерле, иң мөкатдәс, иң изге зат:
Туган илең,
Туган телең,
Туган анаң!

# III бүлек. *Г. Афзалның пейзаж лирикасында туган як темасы*

- Гамил Афзал шигъриятендә пейзаж лирикасы зур урын алып тора.
- Лирик герой дөньяның матурлыгына дан җырлый.





# “Өянкеләр моңы”

**Каен урманының бирге өлеше**
**Киртәләргә орынып туктала.**
**Гүя монда табигать һәм кеше**
**Бер-берсенә карап соклана.**



# “Имән” шигырендә шагыйрьнең лирик герое йөзьяшәр имән.

- . **Бу шигырьдә Имән, кешенең туган якта гына көчле була алуын, тамыр җәеп кояш астында үз урынын таба алуын символлаштыра.**



# Гамил Афзал иҗатында Сандугач образы еш очрый.



- Сандугач шагыйрьнең шигъриятендә өмет, хыял, матурлык символы булып тора. Тормыш урманы караңгы булса да, кадерле, газиз, чөнки ул туган нигез:
- “Кендегең киселгән җирдә сандугач сайравы җирсетә”. (“Ностальгия”)

# Татарстан таңнары

Дулкынланып тирбәлә җыр:

“...Сандугач кунмас инде,

Ямьле булса да торган җир,

Туган җир булмас инде”.



Табигать лирикасында Гамил Афзал тудырган образлар искиткеч бай, кызык һәм гыйбрәтле. Боларның барысы да бер максатка хезмәт итә: халыкка – иманын, милләткә – рухын, адәмгә – әхлагын кайтару.



# Йомгаклау



Гамил Афзал – чын көрәшче, нык рухлы, чиста иманлы шәхес.

Шагыйрь туган җиргә, аның табигатенә, халыкның гореф-гадәтләренә, әхлак-кануннарына хөрмәт белән карап яши, Ватанга тугрылыклы булуын иҗатында ачык чагылдыра.

Һәр күңелнең бизмәне бар,

Минем дә бар бизмән:

Таулар, ташлар аерылса да,

Туган илдән бизмәм.

# Кулланылган әдәбият


- 1. Әдипләребез. – Казан, 2009.
- 2. Гамил Афзал. Гомер кичүләре. – Казан, 2000.
- 3. Гамил Афзал. Рәхмәт! – Казан, 2009.
- 4. Гамил Афзал. Сайланма әсәрләр. 3 томда. - Казан, 2004.
- 5. Гамил Афзал. Сайланма әсәрләр. - Казан, 2004.
- 6. Шәехов Л. Шагыйрь белән соңгы сөйләшү.: Гамил Афзал турында. «Ялкын» -2001 №5.
- 7.Ленар Шәех . Күңелдә моң - сагыш тирбәлә: Юксыну ( Шагыйрь Гамил
- Афзал). «Шәһри Казан.»- 2004.-12 июнь.
- 8. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбияты укыту методикасы/ - Казан: Татарстан нәшрияты, 2000.-335б.
- 9. Бехер М. Любовь моя поэзия/ - Москва: изд-во Художественная литература, 1965. -385с.

# ИГЪТИБАРЫГЫЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ!

